Ләйлә Әхмәдиева

# Яратмасам сине ак кәгазьгә язылыр иде микән шигырьләр.



# СИНЕҢ ХАКТА.

Синең белән очраштырган өчен
Мин язмышка бик тә рәхмәтле,
Син үзгәрттең минем язмышымны
Һәм яңадан ачтың галәмне.

Синең белән танышканнан бирле
Уйларымнан минем китмисең,
Күңелемә кереп урнаштың да
“ Мин синеке” генә бит дисең.

Синең йөзең минем кузалдымда
Ә тавышың чыңлый колакта,
Минем уйлар бары синең хакта
Ә йөрәгем сиңа ашкына.

28.09.2013 18:10

# Син генә...

Күңелдәге уйларымны
Шигъри юлларга салам,
Бары синең хакта гына
Мин бит шигырьләр язам.

Минем күзләр синдә генә
Уйларымда син генә,
Синең назлы карашыңны
Күрергә телим көн дә.

Нәрсә генә эшләсәм дә
Уйларымнан чыкмыйсың,
Минем сине яратканны
Син әлегә белмисең.

Синең миңа язганыңны
Зарыгып көтеп алам,
Без бергә булырбыз диеп
Мин өметләнеп калам.




06.10.2013 16:20


# СИН ҺӘМ МИН

Синен ягымлы карашың
Дәрт бирә йөрәгемә.
Син минеке булсаң әгәр
Булырбыз без гел бергә.

Син бәхетлеме дисәләр
Мин әйе дияр идем.
Синең минем яннарымда
Булуың теләр идем.

Синең белән китәр идем
Бу дөньяның читенә.
Минем белән булсаң әгәр
Кирәк түгел беркемдә.

Күзкәйләрең сихерләде
Син дип тибә йөрәгем.
Уйларымда бары тик син
Сине яратам бит мин.




17.10.2013 19:40

# СИҢА...

Сине күрәсе көнне
Күңел зарыгып көтә,
Бары тик сине генә
Ул бит бик якын итә.

Син диеп кенә яшим бит
Мин хәзер һәр көнемне,
Сине күрү нинди шатлык
Икәнен син белдеңме?

Сине күрсәм йөрәккәем
Чыгардай булып тибә,
Сине күреп сөйләшәсе
Минем бит бик тә килә.

Сине күргән чакта минем
Күңелне шатлык баса,
Сине күрәсе көннәрем
Күп булса иде алда.

Кайчак үземне аңламыйм
Йөрәк барсын хәл итә,
Хыялымда ул бит мине
Синең янына илтә.

14.01.2014 19:15

Sevelina.ru

# СИҢА ГЫНА…

Очрадың да минем юлларымда
Тынычлыгымны алдын син,
Сине тәүге кургән көннән алып
Уйларыма кереп калдың син.

Сиңа булган сою хисләремне
Шигъри юлларыма салдым мин
Шул ягымлы күз карашын белән
Минем күңелемдә калдың син.

Белмим нәрсәң белән җәлеп иткәнсеңдер
Минем йөрәк сине яратты,
Әллә елмаюың, әллә күз карашың
Мине бары сиңа каратты.

Йөрәккә бит әмер биреп булмый
Яратма син аны диеп тә,
Сине генә уйлый бит ул хәзер
Тибә бит ул тик син диеп лә.

Күпме генә инде тырышсам да
Сине хәзер оныта аламмы?
Сиңа булган сөю хисләремдә
Мин бер үзем генә янаммы?

Үткәннәрне искә төшерәм дә
Елыйсылар килә кайвакыт,
Язмыш безне очраштырган икән
Ник кушмады икән сон вакыт?

Минем сорауларым бик күп тә бит
Тик җаваплар гына табылмый,
Йөрәгемнең син дип янулары
Тик беразга булса да тынмый

08.04.2014 18:35

Сиңа гашыйк булуымны
Мин сизмичә дә калдым,
Йөрәгемнең иң түрендә
Син минем урын алдың.

Мин сине бик яратам
Син шуны беләсеңме?
Күземдәге очкыннарны
Син димен күрәсеңме?

Сине генә көтә күңел
Сине генә сагына,
Синең яннарыңа һәркөн
Очар коштай ашкына.

# СИНЕ ГЕНӘ.

28.05.2014 19:00
**Көндезләрен уемда син**

# БӘХЕТЕ<br>М<br>СИН.

Юлларыма чыкмыйсың син
Каршыма очрамыйсың,
Сине генә яратам мин
Син генә аңламыйсың.

Тормышыма үтеп кереп
Биләдең йөрәгемне,
Юлларымда маяк булып
Яктырттың күкләремне.

Син күрү миңа бәхет
Икәнен сизәсеңме?
Көндәлдәге уйларыңны
Миңа сөйләмәссеңме?

Төшемә дә керәсең син
Ә бүген күрдем өндә,
Сине күрү шатлыгыннан
Йөрәгем дөп-дөп тибә.

20.08.2014 07:35

# Уйламадым...

Уйламадым, очратырмын диеп
Сине тормыш сукмагымда,
Очраттым мин һәм яраттым
Хәзер син бит уйларымда.

Уйламадым, булырсың дип
Күңелемнең кояшы.
Тормышыма үтеп кереп
Син үзгәрттең дөньямны.

Уйламадым, сагынырмын диеп
Синең белән юллар аерылгач,
Уйларымда көн дә сиңа барам
Йөрәккәем өзелеп сагынгач.

06.10.2014 19:00

# Хыялымда син.

Йөрәгем сина эндәшә
Күңелем сине көтә,
синең белән очрашуны
һәркөнне өмет итә.

Сине күрмәм микән диеп
Кон дә җиһанны күзлим,
Кайчан да бер очрашырбыз
Мин өметемне өзмим.

28.11.2014 21:26

# Яратам.

Бөтен җаным-тәнем белән
Мин бит сине яратам.
Уйларым белән көн дә
Сиңа әйләнеп кайтам.

Хыялый бер кызчык кебек
Мин сиңа гашыйк булдым
Йөрәгемнең иң түрендә
Син җаным урын алдың.

Очрашырга теләсәм дә
Чакырымнар аера,
Хыялымда канатланып
Очам синең янына.

Сине ничек сагынуымны
Мин үзем генә беләмен,
Күрәсе килгән көннәрдә
Төшләремә керәсен.

27.01.2016 22:37